КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 20 гыйнвар г.Казань № б-75

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 170[1] статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 52[1] статьясы нигезендә 2023 – 2034 елларга Татарстан Республикасының бюджет фаразын (боерыкка теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 гыйнвар, б-118 нче; 2018 ел, 30 гыйнвар, б-176 нчы; 2018 ел, 28 декабрь, б-3706 нчы; 2019 ел, 30 декабрь, б-3550 нче; 2021 ел, 26 гыйнвар, б-115 нче; 2022 ел, 22 гыйнвар, б-77 нче боерыклары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 20 гыйнвар, б-75 нче
боерыгы белән расланды

# 2023 – 2034 елларга Татарстан Республикасының бюджет фаразы

2023 – 2034 елларга Татарстан Республикасының бюджет фаразы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2015 ел, 15 сентябрь, 676 нчы карары белән расланган Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибенә нигезләнеп эшләнде.

Бюджет фаразында 12 елга, ягъни 2034 елга кадәрге чорга бурыч, салым һәм бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм Таатарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп параметрлары билгеләнә.

Бюджет фаразын формалаштыру алымнары үткән еллардагы республика бюджет сәясәтен гамәлгә ашыру йомгакларына нигезләнә.

## Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты үтәлешенең төп йомгаклары

2021 елда Татарстан Республикасы бюджетының үтәлеше, үткән ел белән чагыштырганда, республиканың төп макроикътисадый күрсәткечләре үсү шартларында башкарылды. Шул ук вакытта әлеге үсеш «компенсация» характерын да йөртә. Бу яңа коронавирус инфекциясе белән көрәшү кысаларында чикләү чаралары киң кулланылган һәм дөньяда икътисадый үсеш динамикасының кимүе күзәтелгән 2020 нче пандемия елыннан соң икътисадтагы торгызу процесслары белән бәйле. 2021 елда дөньякүләм нефть базарында бәяләр вәзгыяте билгеле бер уңайлы дәрәҗәдә стабильләшүне билгели торган икътисадый процессларның җанлануы нәтиҗәсендә 2021 елда Татарстан Республикасы бюджетының керем өлеше үткән ел дәрәҗәсен генә түгел, ә кризиска кадәрге 2019 ел күрсәткечләрен дә арттырып үтәлде. Салым һәм салым булмаган керемнәр Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына 336,1 млрд.сум күләмендә керде, бу 2020 елга караганда 80,3 млрд.сумга (31,4 процентка) һәм 2019 елга караганда 37 млрд.сумга (12,4 процентка) күбрәк. Татарстан Республикасы элеккечә Идел буе федераль округы субъектлары арасында салым һәм салым булмаган керемнәрне мобилизацияләү буенча лидер булып кала һәм Россия төбәкләренең беренче унлыгына керә.

2021 елда Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты чыгымнарын финанслау заем чыганакларыннан файдаланмыйча, шул исәптән федераль бюджет кредитларын җәлеп итмичә тәэмин ителгән иде. Социаль йөкләмәләрне тулысынча үтәү дә һәм башка юнәлешләр буенча кирәкле финанслау да гамәлгә ашырылган иде. 2021 ел нәтиҗәләре буенча республика бюджеты профицит белән үтәлде, 2020 ел йомгаклары буенча бурыч йөкләнеше дәрәҗәсе 34,5 процент урынына 47,5 процент итеп тәэмин ителде.

## Озак сроклы чорга салым, бюджет һәм бурыч сәясәтен формалаштыруның төп алымнары

Озак сроклы чорда Татарстан Республикасының салым, бюджет һәм бурыч сәясәтен гамәлгә ашыруның төп максатлары – бюджет системасының тотрыклылыгын һәм балансылыгын саклап калу, халыкның тормыш сыйфатын яхшырту.

Фаразлана торган чорда салым сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты керемнәре, икътисад секторларына салым салуның төп параметрлары саклап калынуын исәпкә алып, 2034 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләрен бәяләүдән чыгып билгеләнә. Салым һәм салым булмаган керемнәрне фаразлаганда үткән елларда барлыкка килгән тенденцияләр, геосәяси факторларның тулаем дәүләт социаль-икътисадый үсешенә йогынтысы исәпкә алынды. Озак сроклы чорда бюджет керемнәрен формалаштыру икътисадый үсешнең уртачарак темплары шартларында гамәлгә ашырылачак. Гомумән алганда, бюджет керемнәрен формалаштыру сәясәте салым һәм салым булмаган керемнәр буенча законнарны камилләштерү, ташламаларның нәтиҗәлелеген бәяләү, дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү механизмнарын кулланып системалы якын килүгә нигезләнә.

2034 елга кадәр Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп керем чыганаклары саклана. Бу – табышка салым, физик затлар керемнәренә салым, акцизлар, мөлкәткә салым.

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының балансылыгын тәэмин итү максаты белән бюджетка керемнәрне мобилизацияләү буенча киңәйтелгән чаралар комплексын алга таба гамәлгә ашыру күздә тотыла.

Керемнәр үсеше эшлекле климатны яхшырту, сәнәгать җитештерүен үстерү, республика икътисадына инвестицияләр күләме арту, керемнәр белән идарә итү нәтиҗәлелеген арттыру исәбенә тәэмин ителәчәк.

Татарстан Республикасының озак сроклы бюджет сәясәтен гамәлгә ашырганда төбәк һәм җирле бюджетларның тотрыклылыгын тәэмин итү, бюджет законнары таләпләрен һәм чикләүләрен катгый үтәү, кабул ителгән чыгым йөкләмәләрен максатчан һәм нәтиҗәле үтәү, эчке чыганакларны мобилизацияләү, нәтиҗәсез чыгымнарны киметү, бюджет чыгымнарының үзара бәйләнешен билгеләү һәм аларның дәүләт сәясәтенең билгеләнгән максатларына йогынтысын арттыру бурычы саклана.

Озак сроклы чорга бюджет сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыру түбәндәге төп бурычларны хәл итүдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлекләрен һәм структураларын алга таба камилләштерү;

илкүләм проектларын берсүзсез үтәү һәм аларда каралган индикаторларга ирешү;

республиканың дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләре челтәрен оптимальләштерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

дәүләт мөлкәтеннән һәм муниципаль мөлкәттән файдалану нәтиҗәлелеген арттыру;

республиканың дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүне инвентаризацияләү, аларның эшләвен тәэмин итүнең табигый һәм финанс нормаларын (нормативларын) куллану өлкәсен киңәйтү;

икътисадның реаль секторына дәүләт ярдәме күрсәтү өлкәсендә бюджет сәясәтен камилләштерү, юридик затларга субсидияләр бирү нәтиҗәлелеген бәяләү;

дәүләткә карамаган (муниципаль булмаган) оешмаларны социаль-мәдәни өлкәгә, шул исәптән дәүләт хосусый партнерлыгы, муниципаль хосусый партнерлык кысаларында җәлеп итү темпларын арттыру;

халыкка социаль ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеген арттыру;

бюджетара трансфертлар бирүнең һәм алардан файдалануның нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын арттыру;

сатып алулар өлкәсендә алдан һәм аннан соңгы контроль процедураларын камилләштерү;

дәүләт секторларында һәм муниципаль секторларда финанс менеджментының сыйфатын яхшырту;

иҗтимагый финансларның ачык һәм үтә күренмәле булуын, ихтыяри салым даирәләрен киңәйтүне, гражданнарны бюджет мәсьәләләрен хәл итү буенча фикер алышу һәм алар буенча карар кабул итү, аларның эффективлыгын һәм нәтиҗәлелеген җәмәгатьчелек контролендә тоту процедураларына киң җәлеп итүне тәэмин итү.

Алдагы чорга Татарстан Республикасы бурыч сәясәтенең төп максатлары һәм бурычлары:

Татарстан Республикасының финанс тотрыклылыгы һәм түләү сәләте сакланышын икътисадый яктан имин дәрәҗәдә тәэмин итә торган бурыч йөкләнеше дәрәҗәсендә тәэмин итү;

еллар буенча бурыч йөкләнешен тигез итеп бүлү;

хезмәт күрсәтү кыйммәтен минимальләштерү максатларында дәүләт бурычы структурасын оптимальләштерү;

бюджет кредитлары буенча бурычны реструктуризацияләү шартларын катгый үтәү;

федераль бюджеттан алынган бюджет кредитлары буенча килешүләрдә билгеләнгән чикләүләрне үтәү.

### Татарстан Республикасының<br>икътисадый үсеше сценарийлары тасвирламасы

2034 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 8 сентябрендәге утырышында хупланган 2023 – 2025 елларга республика үсеше фаразы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше фаразының төп параметрлары турында, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы турында, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты турында» 2022 ел, 13 сентябрь, 986 нчы карары), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты һәм 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы

социаль-икътисадый үсешенең озак вакытлы фаразы хакында» 2015 ел, 16 май, 347 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы параметрларын исәпкә алып, ике (база һәм консерватив) вариантта формалаштырылды.

## Демографик күрсәткечләр

2021 елга Татарстан Республикасы халкы саны 3 890,3 мең кеше (уртача бер елга) тәшкил итте һәм 2020 ел белән чагыштырганда 8,2 мең кешегә кимеде.

Фаразның база варианты буенча даими халык саны 2034 елга фаразлана торган уңай миграция саны арту һәм халыкның туучылар саны исәбенә 3 911,4 мең кеше (уртача елга) тәшкил итәчәк.

Фаразның консерватив варианты буенча 2034 елга даими халык саны 3 909,9 мең кеше (уртача бер елга) тәшкил итәчәк.

Даими халык саны фаразына 2021 елның октябре – ноябрендә үткәрелгән 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу йомгаклары Дәүләт статистикасы федераль хезмәте тарафыннан бастырып чыгарылуга бәйле рәвештә халык санын алу чорына керә торган үткән елларның мәгълүматлары төгәлләштерелгәннән соң төзәтмәләр кертеләчәк.

## Икътисадый күрсәткечләр

Озак сроклы перспективада Татарстан Республикасының тулаем төбәк продукты динамикасы билгеләнә торган икътисадның төп секторларын үстерү фаразлары түбәндәге характеристикалардан гыйбарәт.

Эшчәнлекнең житештерү төрләрен үстерүнең фараз параметрларын исәпләгәндә, бер яктан, товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең глобаль базарларында конкуренция артуы, сату һәм продукция китерү базарларында киеренкелек, икенче яктан – төп фондларны техник модернизацияләү һәм яңарту хисабына производстволарның конкурентлык сәләтен арттыруга, яңа югары нәтиҗәле производстволар булдыруга һәм югары технологияле продукция чыгаруны үзләштерүгә, шулай ук импортны алыштыру процессларын киңәйтүгә юнәлтелгәнлек исәпкә алынды.

2022 елда Россия икътисады яшәешенең тышкы һәм эчке шартлары кардиналь рәвештә үзгәрде. Санкцияләр шартларында икътисадның тотрыклылыгын арттыру максатларында икътисадтагы вәзгыятьне тотрыклыландыру, бизнес чыгымнарын киметү, эш урыннарын саклап калу буенча федераль һәм республика чаралары үз вакытында кабул ителде, алар күпчелек очракта тискәре социаль-икътисадый кәтиҗәләрне киметте. Шул ук вакытта икътисад үсешенең агымдагы шартлары билгесезлекнең югары дәрәҗәдә булуы белән характерлана.

Фаразның база варианты ресурс чикләүләрен бетерү буенча кирәкле чаралар күреләчәген, шулай ук икътисадка ярдәм итү буенча барлык чаралар комплексын нәтиҗәле гамәлгә ашыруга, геосәяси һәм икътисадый тотрыксызлыкка бәйле тискәре нәтиҗәләрне киметүгә, житештерү-логистика чылбырлары структурасын үзгәртеп оештыруга, житештерелә торган продукциянең конкурентлык сәләтен арттыру һәм озак сроклы тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән актив дәүләт сәясәтен үткәрү каралачак.

2023 – 2025 елларда фаразның база варианты буенча тулаем төбәк продуктының

уртача еллык үсеш темплары чагыштырма бәяләрдә 102,2 процент, 2026 – 2034 елларда 102,8 процент булыр дип фаразлана.

2023 – 2025 елларда сәнәгать җитештерүе уртача 102,2 процент, 2026 – 2034 елларда 102,5 процент дәрәҗәсендә артачак.

Сәнәгать җитештерүе үсешенә, гадәттәгечә, башка тармаклар үсеше белән бергә нефть-газ химиясе һәм машина төзелеше комплекслары төп өлеш кертәчәк. Фаразлана торган чорда берничә зур инвестиция проектларын планлаштырылган куәткә чыгару көтелә, шул ук вакытта кайбер проектларның гамәлгә ашыру срокларын мөмкин кадәр киметү күздә тотыла.

Республикада алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре, махсус икътисадый зоналар, индустриаль парклар, технопарклар, сәнәгать парклары булдырылды һәм алар уңышлы үсеш алды.

Фаразлана торган чорда авыл хуҗалыгы продукциясе күләмнәре үсешенең еллык темплары, тармак дәүләт программасы нигезендә чагыштырма бәяләрдә 101,8 процент дәрәҗәсендә каралды.

«Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме үсешенең уртача еллык темплары, фараз буенча, 2023 – 2025 елларда чагыштырма бәяләрдә 100,0 процент, 2026 – 2034 елларда 101,8 процент тәшкил итәчәк.

2023 – 2025 елларда уртача ваклап сату әйләнеше чагыштырма бәяләрдә 103,4 процент, 2026 – 2034 елларда 103,5 процент дәрәҗәсендә артачак. Ваклап сату өлкәсендә фаразлана торган уңай тенденцияләрнең төп факторлары: халыкның акчалата керемнәре үсеше арту, инфляциянең динамикасы туктап торган дәрәҗәдә булу, үз илебез предприятиеләре тарафыннан куллланучылар үзенчәлекләре буенча халык таләпләренә җавап бирә торган конкурентлыкка сәләтле продукция чыгарылышын арттыру.

2023 – 2025 елларда төп капиталга инвестицияләр үсешенең уртача еллык темплары чагыштырма бәяләрдә 102,0 процент, 2026 – 2034 елларда 104,7 процент дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана.

Фаразның консервив вариантында икътисад үсеше уртача дәрәҗәдә озак сроклы темпларда булуы белән характерлана.

2023 – 2025 елларда тулаем төбәк продуктының уртача еллык үсеш темплары чагыштырма бәяләрдә 101,0 процент, 2026 – 2034 елларда 102,4 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

2023 – 2025 елларда сәнәгать җитештерүе уртача чагыштырма бәяләрдә 101,3 процент, 2026 – 2034 елларда 102,1 процент дәрәҗәсендә үсәчәк.

Фаразлана торган чорда, база вариантындагы кебек үк, авыл хуҗалыгы продукциясе үсешенең уртача еллык темплары чагыштырма бәяләрдә 101,8 процент дәрәҗәсендә каралды.

«Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме динамикасы 2023 – 2025 елларда уртача бер елга чагыштырма бәяләрдә 98,0 процент, 2026 – 2034 елларда 101,3 процент тәшкил итәчәк.

2023 – 2025 елларда ваклап сату әйләнеше уртача чагыштырма бәяләрдә 101,5 процент, 2026 – 2034 елларда 102,5 процент дәрәҗәсендә артачак.

2023 – 2025 елларда төп капиталга инвестицияләр үсеше темпы уртача чагыштырма бәяләрдә 100,8 процент, 2026 – 2034 елларда 102,9 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

## Хезмәт һәм халыкның эш белән тәэмин ителеше күрсәткечләре

Татарстан Республикасында озак сроклы перспективада социаль күрсәткечләрне яхшырту – икътисадта эш белән тәэмин ителүчеләр санын арттыру һәм эшсезлек дәрәҗәсен киметү фаразлана.

Яңа производстволарны гамәлгә кертүне, республикага югары квалификацияле белгечләр җәлеп итү буенча актив дәүләт сәясәтен, хәзерге вакытта хезмәт базарында булмаган халык катламын хезмәт базарына җәлеп итүне күздә тота торган база варианты буенча, кече эшмәкәрлекне үстерүне исәпкә алып, икътисадта эш белән тәэмин ителүчеләр санын 2034 елда 1 995,0 мең кешегә кадәр арттыру фаразлана. Фаразның база варианты буенча 2034 елда эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) 3,3 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

Консерватив вариант буенча республикада икътисадта эш белән тәэмин ителүчеләр саны 2034 елда 1 994,0 мең кеше тәшкил итәчәк. Эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) 3,3 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

## Бюджет фаразын формалаштыру шартлары, озак сроклы чорга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикалары фаразы

2023 – 2034 елларга керемнәр һәм чыгымнар буенча Татарстан Республикасы бюджет фаразы 2034 елга кадәрге Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы нигезендә ике – база һәм консерватив вариантларда эшләнде.

## Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен фаразлаганда Россия Федерациясе законнарына кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынды.

Татарстан Республикасы бюджетының төп салым керемнәре буенча керемнәр фаразы 2034 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше фаразына салынган икътисадый күрсәткечләр динамикасыннан чыгып төзелде.

Татарстан Республикасы бюджетының кайбер керемнәре өчен инфляция күләменә ясалган индексация яки тулаем эчке продуктның күтәелә торган үсеше исәпкә алынды.

## Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары

Бюджет фаразын эшләү кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының исәп-хисабы, инфляция күләменә, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт программалары буенча ясалган индексацияне исәпкә алып, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары шартларында гамәлгә ашырылды.

Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланды.

Бюджет фаразын гамәлгә ашыру процессында
барлыкка килә торган төп килеп чыгу куркынычлары һәм
аларны профилактикалау механизмнары

Республиканың бюджет параметрларын бәяләү һәм аларның балансссыз булу рискларын минимальләштерү өчен шартлар тудыру мөмкинлеге стабильле озак сроклы бюджет тотрыклылыгын тәэмин итүнең мөһим факторлары булып тора.

Бюджетка яный торган куркынычларны минимальләштерүнең гомуми алымнары, кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру чыгымнарын киметмичә, Татарстан Республикасының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен тәэмин итү мөмкинлегеннән гыйбарәт. Шуны исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар керемнәре кимегән очракта, бюджет балансслылыгын тәэмин итү максатларында, беренче чиратта, шартлы раслана торган чыгымнар кимételәчәк.

Бюджет фаразын гамәлгә ашыру рисклары халыкара финанс һәм икътисадый тотрыксызлык шартларында Татарстан Республикасының бюджет системасы үсешенә йогынты ясый торган кайбер тышкы һәм эчке факторлар барлыкка килүгә бәйле.

Бюджет рискларын профилактикалау тиешле рискларны тормышка ашыруның тискәре нәтиҗәләрен минимальләштерү буенча алдан ук ачыклау һәм чаралар күрү белән тәэмин ителә.

Икътисадый тотрыксызлык шартларында Татарстан Республикасы бюджет системасы өчен аеруча иң тискәре нәтиҗәләргә һәм рискларга түбәндәгеләр керә:

республика социаль-икътисадый үсешенең тулаем төбәк продукты, табышлы оешмалар табышы, хезмәт хакы фонды, шулай ук төп капиталга инвестицияләр кебек фаразлана торган параметрларына (динамикасына һәм күләмнәренә) ирешмәү;

эшсезлек арту;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр һәм бюджеттан тыш эшчәнлектән керемнәр кимү;

федераль бюджеттан бирелә торган бюджетара трансфертларны киметү;

өстәмә чыгым йөкләмәләрен тапшыру;

Россия Федерациясе субъектлары бюджетларын «авырайта торган» Россия Федерациясе салым һәм бюджет законнарына үзгәреш кертү.

Бюджет рискларын минимальләштерү чаралары:

Татарстан Республикасының керем потенциалын арттыру;

социаль әһәмиятле чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен республика һәм җирле бюджетларның керем өлешен максималь тулыландыру;

Татарстан Республикасы дәүләт бурычын икътисадый яктан имин булган дәрәҗәдә тәэмин итү;

Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар үтәлешенә җентекле анализ ясау;

халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.

Озак сроклы чорда Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль финанслары белән идарә итү сыйфатын яхшырту һәм бюджет акчасын файдалану нәтиҗәлелеген арттыру эшен дәвам итәргә кирәк.

# 2034 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы буенча төп күрсәткечләр

(база варианты)

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Фараз | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2031 ел | 2032 ел | 2033 ел | 2034 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Демографик күрсәткечләр | | | | | | | | | | | | | |
| Даими халык саны (уртача еллык)[1] | мең кеше | 3 882,9 | 3 880,6 | 3 878,5 | 3 878,5 | 3 878,9 | 3 880,4 | 3 883,2 | 3 888,0 | 3 891,9 | 3 895,8 | 3 903,6 | 3 911,4 |
| Үсеш темплары | үткән елга карата процент | 99,9 | 99,9 | 99,9 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,1 | 100,1 | 100,1 | 100,1 | 100,2 | 100,2 |
| Тулаем төбәк продукты | | | | | | | | | | | | | |
| Тулаем төбәк продукты (тиешле елларның төп бәяләрендә) | млн.сум | 3 869 637,4 | 4 150 300,4 | 4 416 382,6 | 4 665 385,3 | 4 933 055,0 | 5 222 524,5 | 5 528 828,8 | 5 851 868,0 | 6 219 152,7 | 6 604 011,4 | 7 018 195,6 | 7 456 988,6 |
| Тулаем төбәк продуктының физик күләме индексы | даими төп бәяләрдә үткән елга карата процент | 100,8 | 103,2 | 102,7 | 102,7 | 102,8 | 103,0 | 103,0 | 103,0 | 102,7 | 102,6 | 102,6 | 102,6 |
| Сәнәгать җитештерүе | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 4 559 921,9 | 4 905 783,2 | 5 188 030,6 | 5 485 010,5 | 5 790 119,7 | 6 111 273,8 | 6 460 032,8 | 6 830 751,2 | 7 262 903,9 | 7 713 102,5 | 8 181 217,5 | 8 668 649,6 |
| Сәнәгать җитештерүе индексы | үткән елга карата процент | 100,7 | 103,5 | 102,4 | 102,4 | 102,5 | 102,6 | 102,6 | 102,7 | 102,5 | 102,5 | 102,4 | 102,3 |
| Файдалы казылмалар чыгару | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 1 134 577,4 | 1 203 364,2 | 1 250 134,9 | 1 297 574,4 | 1 340 974,9 | 1 385 942,3 | 1 432 539,3 | 1 480 831,6 | 1 532 903,3 | 1 584 109,1 | 1 634 245,3 | 1 685 986,5 |
| Җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 99,4 | 102,2 | 101,6 | 101,6 | 101,1 | 101,1 | 101,1 | 101,1 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| Эшкәртү производстволары | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 3 193 510,6 | 3 459 225,6 | 3 682 682,7 | 3 920 948,7 | 4 171 555,3 | 4 437 204,6 | 4 729 505,6 | 5 041 731,4 | 5 411 261,0 | 5 799 677,7 | 6 207 228,1 | 6 632 676,1 |
| Җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 101,2 | 104,2 | 102,7 | 102,8 | 103,1 | 103,1 | 103,2 | 103,3 | 103,3 | 103,2 | 103,2 | 103,0 |
| Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава кондиционерлау | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп | млн.сум | 169 352,9 | 177 888,3 | 186 949,8 | 195 903,3 | 204 887,9 | 213 244,2 | 220 858,7 | 228 745,2 | 236 913,2 | 245 034,6 | 252 934,5 | 260 573,1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | | | | | | | | | | | | | |
| Җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 100,0 | 101,0 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,4 | 101,2 | 101,0 |
| Су белән тәэмин итү; су чыгару, калдыклар җыюны һәм утилизацияләүне оештыру, пычракларны бетерү эшчәнлеге | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 62 481,0 | 65 305,1 | 68 263,2 | 70 584,1 | 72 701,6 | 74 882,7 | 77 129,2 | 79 443,0 | 81 826,4 | 84 281,1 | 86 809,6 | 89 413,9 |
| Җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 100,4 | 100,5 | 100,8 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| Авыл хуҗалыгы | | | | | | | | | | | | | |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе | млн.сум | 278 170,2 | 283 361,5 | 288 654,1 | 296 788,4 | 305 151,9 | 313 751,0 | 322 592,6 | 331 683,2 | 341 030,0 | 350 640,3 | 360 521,3 | 370 680,8 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү индексы | чагыштырма бәяләрдә үткән елга карата процент | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 |
| Төзелеш | | | | | | | | | | | | | |
| «Төзелеш» икътисадый эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме | тиешле еллар бәяләрендә; млн.сум | 495 207,4 | 521 453,4 | 547 029,6 | 573 975,2 | 606 485,1 | 638 974,5 | 673 893,2 | 712 116,5 | 759 789,1 | 810 670,6 | 864 131,1 | 920 250,4 |
| «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча җитештерү индексы | чагыштырма бәяләрдә үткән елга карата процент | 100,0 | 100,0 | 100,1 | 100,6 | 101,6 | 101,5 | 101,8 | 102,0 | 102,1 | 102,2 | 102,2 | 102,3 |
| Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базары | | | | | | | | | | | | | |
| Ваклап сату әйләнеше | млн.сум | 1 278 781,0 | 1 389 779,2 | 1 503 179,6 | 1 613 332,6 | 1 736 591,2 | 1 869 266,8 | 2 014 022,8 | 2 169 988,7 | 2 333 536,4 | 2 509 410,4 | 2 698 539,7 | 2 901 923,2 |
| Ваклап сату әйләнешенең физик күләме индексы | чагыштырма бәяләрдә үткән елга карата процент | 102,4 | 104,0 | 103,8 | 103,2 | 103,5 | 103,5 | 103,6 | 103,6 | 103,6 | 103,6 | 103,6 | 103,6 |
| Инвестицияләр | | | | | | | | | | | | | |
| Барлык финанслау чыганаклары исәбеннән төп капиталга инвестицияләр күләме | млн.сум | 782 699,1 | 834 357,2 | 897 234,4 | 975 119,7 | 1 066 878,5 | 1 167 271,8 | 1 278 316,7 | 1 399 925,5 | 1 527 273,9 | 1 664 624,7 | 1 810 860,3 | 1 968 053,9 |
| Физик күләм индексы | чагыштырма бәяләрдә үткән елга карата процент | 100,2 | 102,5 | 103,4 | 104,2 | 105,0 | 105,0 | 105,2 | 105,2 | 104,8 | 104,6 | 104,3 | 104,2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хезмәт һәм халыкның эш белән тәэмин ителеше | | | | | | | | | | | | | |
| Икътисадта эш белән тәэмин ителүчеләр саны (уртача еллык) (хезмәт ресурслары балансы методологиясендә) | мең кеше | 1 987,5 | 1 987,7 | 1 988,5 | 1 988,7 | 1 989,2 | 1 990,1 | 1 990,9 | 1 991,6 | 1 992,0 | 1 993,0 | 1 994,0 | 1 995,0 |
| Эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) | эш белән тәэмин ителүчеләргә карата процентта | 3,4 | 3,4 | 3,4 | 3,4 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 |

[1]Даими халык саны (уртача еллык) фаразына Дәүләт статистикасы федераль хезмәте тарафыннан 2021 елның октябре – ноябрендә үткәрелгән 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу йомгаклары басылып чыкканнан соң төзәтмәләр кертеләчәк.

# 2034 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы буенча төп күрсәткечләр

(консерватив вариант)

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Фараз | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2031 ел | 2032 ел | 2033 ел | 2034 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Демографик күрсәткечләр | | | | | | | | | | | | | |
| Даими халык саны (уртача еллык)[1] | мең кеше | 3 881,8 | 3 879,2 | 3 877,0 | 3 877,0 | 3 877,4 | 3 878,9 | 3 881,7 | 3 886,5 | 3 890,4 | 3 894,3 | 3 902,1 | 3 909,9 |
| Үсеш темплары | үткән елга карата процент | 99,9 | 99,9 | 99,9 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,1 | 100,1 | 100,1 | 100,1 | 100,2 | 100,2 |
| Тулаем төбәк продукты | | | | | | | | | | | | | |
| Тулаем төбәк продукты (тиешле елларның төп бәяләрендә) | млн.сум | 3 833 186,3 | 4 024 433,6 | 4 240 666,7 | 4 482 268,5 | 4 713 999,4 | 4 960 586,1 | 5 224 411,3 | 5 508 519,9 | 5 845 320,4 | 6 198 745,0 | 6 576 030,5 | 6 970 309,4 |
| Тулаем төбәк продуктының физик күләме индексы | даими төп бәяләрдә үткән елга карата процент | 100,0 | 101,1 | 101,8 | 102,7 | 102,3 | 102,3 | 102,4 | 102,5 | 102,5 | 102,5 | 102,4 | 102,3 |
| Сәнәгать җитештерүе | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 4 543 250,1 | 4 793 435,6 | 5 059 550,9 | 5 334 403,7 | 5 610 917,5 | 5 895 315,4 | 6 204 232,6 | 6 535 929,7 | 6 918 284,2 | 7 317 050,6 | 7 730 877,8 | 8 162 132,7 |
| Сәнәгать җитештерүе индексы | үткән елга карата процент | 100,3 | 101,5 | 102,2 | 102,1 | 102,1 | 102,1 | 102,2 | 102,3 | 102,1 | 102,1 | 102,1 | 102,0 |
| Файдалы казылмалар чыгару | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 1 132 523,1 | 1 177 380,6 | 1 223 193,3 | 1 250 320,9 | 1 278 100,6 | 1 306 550,1 | 1 335 687,5 | 1 365 531,6 | 1 412 988,5 | 1 460 171,4 | 1 506 360,8 | 1 554 028,0 |
| Җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 99,2 | 100,2 | 101,6 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,1 | 100,1 | 100,1 |
| Эшкәртү производстволары | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 3 178 893,1 | 3 372 861,6 | 3 581 144,6 | 3 818 637,2 | 4 057 400,8 | 4 304 022,5 | 4 575 218,0 | 4 868 227,9 | 5 194 015,9 | 5 536 215,2 | 5 894 185,8 | 6 267 814,9 |
| Җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 100,8 | 102,1 | 102,4 | 102,9 | 102,9 | 102,8 | 102,9 | 103,1 | 102,7 | 102,7 | 102,7 | 102,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава кондиционерлау | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 169 352,9 | 177 888,3 | 186 949,8 | 194 861,5 | 202 714,4 | 209 860,1 | 216 197,9 | 222 727,1 | 229 453,4 | 236 382,9 | 243 521,6 | 250 876,0 |
| Җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 100,0 | 101,0 | 101,5 | 101,0 | 101,0 | 101,0 | 101,0 | 101,0 | 101,0 | 101,0 | 101,0 | 101,0 |
| Су белән тәэмин итү; су чыгару, калдыклар җыюны һәм утилизацияләүне оештыру, пычракларны бетерү эшчәнлеге | | | | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 62 481,0 | 65 305,1 | 68 263,2 | 70 584,1 | 72 701,7 | 74 882,7 | 77 129,2 | 79 443,1 | 81 826,4 | 84 281,1 | 86 809,6 | 89 413,8 |
| Җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 100,4 | 100,5 | 100,8 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| Авыл хуҗалыгы | | | | | | | | | | | | | |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе | млн.сум | 278 170,2 | 283 361,5 | 288 654,1 | 296 788,4 | 305 151,9 | 313 751,0 | 322 592,6 | 331 683,2 | 341 030,0 | 350 640,3 | 360 521,3 | 370 680,8 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү индексы | чагыштырма бәяләрдә үткән елга карата процент | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,8 |
| Төзелеш | | | | | | | | | | | | | |
| «Төзелеш» икътисадый эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме | тиешле еллар бәяләрендә; млн.сум | 476 734,5 | 493 830,2 | 518 027,8 | 541 383,6 | 568 008,9 | 597 702,1 | 630 198,0 | 665 779,0 | 710 349,5 | 757 920,2 | 807 902,0 | 860 369,6 |
| «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча җитештерү индексы | чагыштырма бәяләрдә үткән елга карата процент | 96,0 | 98,0 | 100,0 | 100,2 | 100,4 | 100,6 | 100,8 | 101,0 | 102,1 | 102,2 | 102,2 | 102,3 |
| Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базары | | | | | | | | | | | | | |
| Ваклап сату әйләнеше | млн.сум | 1 237 459,4 | 1 312 696,9 | 1 392 508,9 | 1 484 414,5 | 1 582 385,8 | 1 686 823,3 | 1 798 153,6 | 1 916 831,8 | 2 039 413,2 | 2 169 833,7 | 2 308 594,5 | 2 456 229,1 |
| Ваклап сату әйләнешенең физик күләме индексы | чагыштырма бәяләрдә үткән елга карата процент | 100,5 | 102,0 | 102,0 | 102,5 | 102,5 | 102,5 | 102,5 | 102,5 | 102,5 | 102,5 | 102,5 | 102,5 |
| Инвестицияләр | | | | | | | | | | | | | |
| Барлык финанслау чыганаклары исәбеннән төп капиталга инвестицияләр күләме | млн.сум | 770 695,0 | 821 368,2 | 882 363,0 | 946 993,5 | 1 017 357,0 | 1 096 128,9 | 1 181 007,6 | 1 272 458,9 | 1 360 394,8 | 1 452 969,6 | 1 547 329,8 | 1 646 207,3 |
| Физик күләм индексы | чагыштырма бәяләрдә үткән елга карата процент | 98,1 | 101,5 | 102,8 | 102,9 | 103,1 | 103,4 | 103,5 | 103,5 | 102,7 | 102,5 | 102,3 | 102,2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хезмәт һәм халыкның эш белән тәэмин ителеше | | | | | | | | | | | | | |
| Икътисадта эш белән тәэмин ителүчеләр саны (уртача еллык) (хезмәт ресурслары балансы методологиясендә) | мең кеше | 1 987,0 | 1 987,2 | 1 988,0 | 1 988,3 | 1 988,6 | 1 989,2 | 1 990,1 | 1 990,9 | 1 991,6 | 1 992,0 | 1 993,0 | 1 994,0 |
| Эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) | эш белән тәэмин ителүчеләргә карата процентта | 3,4 | 3,4 | 3,4 | 3,4 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 | 3,3 |

[1]Даими халык саны (уртача еллык) фаразына Дәүләт статистикасы федераль хезмәте тарафыннан 2021 елның октябре – ноябрендә үткәрелгән 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу йомгаклары басылып чыкканнан соң төзәтмәләр кертеләчәк.

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының һәм
Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикалары фаразы

(база варианты, млрд.сум)

| Төп характеристикаларның исеме | 2023 ел | | 2024 ел | | 2025 ел | | 2026 ел | | 2027 ел | | 2028 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты |
| Керемнәр – барлыгы, | 404,5 | 344,0 | 430,9 | 367,4 | 433,7 | 366,9 | 444,8 | 376,2 | 456,5 | 386,0 | 469,4 | 396,8 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| салым һәм салым булмаган | 342,5 | 281,9 | 366,3 | 302,6 | 390,9 | 323,9 | 401,5 | 332,7 | 412,7 | 342,0 | 425,1 | 352,3 |
| кире кайтарылмый торган түләүләр | 62,0 | 62,1 | 64,6 | 64,8 | 42,8 | 43,0 | 43,3 | 43,5 | 43,8 | 44,0 | 44,3 | 44,5 |
| Чыгымнар – барлыгы, | 431,6 | 371,1 | 458,1 | 394,6 | 461,0 | 394,3 | 472,0 | 403,4 | 483,6 | 413,1 | 496,4 | 423,8 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү | | 336,9 | | 347,4 | | 333,6 | | 341,3 | | 349,5 | | 358,6 |
| Дефицит (профицит) | -27,1 | -27,1 | -27,2 | -27,2 | -27,3 | -27,4 | -27,2 | -27,2 | -27,1 | -27,1 | -27,0 | -27,0 |
| Керемнәр – барлыгы, | 482,6 | 407,8 | 496,3 | 419,2 | 508,9 | 429,8 | 521,5 | 440,3 | 534,3 | 451,0 | 547,5 | 462,0 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| салым һәм салым булмаган | 437,8 | 362,8 | 451,0 | 373,7 | 463,1 | 383,8 | 475,2 | 393,8 | 487,5 | 404,0 | 500,2 | 414,5 |
| кире кайтарылмый торган түләүләр | 44,8 | 45,0 | 45,3 | 45,5 | 45,8 | 46,0 | 46,3 | 46,5 | 46,8 | 47,0 | 47,3 | 47,5 |
| Чыгымнар – барлыгы, | 509,5 | 434,7 | 523,1 | 446,0 | 535,6 | 456,5 | 548,1 | 466,9 | 560,8 | 477,5 | 573,9 | 488,4 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү | | 367,8 | | 377,3 | | 386,2 | | 395,0 | | 404,0 | | 413,2 |
| Дефицит (профицит) | -26,9 | -26,9 | -26,8 | -26,8 | -26,7 | -26,7 | -26,6 | -26,6 | -26,5 | -26,5 | -26,4 | -26,4 |

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының һәм
Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикалары фаразы

(консерватив вариант, млрд.сум)

| Төп характеристикаларның исеме | 2023 ел | | 2024 ел | | 2025 ел | | 2026 ел | | 2027 ел | | 2028 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты |
| Керемнәр – барлыгы, | 394,4 | 335,9 | 421,4 | 359,1 | 432,6 | 366,2 | 443,6 | 375,4 | 453,3 | 383,5 | 463,2 | 391,9 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| салым һәм салым булмаган | 332,4 | 273,8 | 356,8 | 294,3 | 389,8 | 323,2 | 400,3 | 331,9 | 409,5 | 339,5 | 418,9 | 347,4 |
| кире кайтарылмый торган түләүләр | 62,0 | 62,1 | 64,6 | 64,8 | 42,8 | 43,0 | 43,3 | 43,5 | 43,8 | 44,0 | 44,3 | 44,5 |
| Чыгымнар – барлыгы, | 421,7 | 363,2 | 450,8 | 388,5 | 464,9 | 398,5 | 475,8 | 407,6 | 485,4 | 415,6 | 495,2 | 423,9 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү | | 329,7 | | 342,0 | | 337,2 | | 344,9 | | 351,6 | | 358,6 |
| Дефицит (профицит) | -27,3 | -27,3 | -29,4 | -29,4 | -32,3 | -32,3 | -32,2 | -32,2 | -32,1 | -32,1 | -32,0 | -32,0 |
| Керемнәр – барлыгы, | 473,8 | 400,7 | 485,0 | 410,1 | 496,5 | 419,7 | 508,2 | 429,5 | 519,8 | 439,2 | 531,2 | 448,8 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| салым һәм салым булмаган | 429,0 | 355,7 | 439,7 | 364,6 | 450,7 | 373,7 | 461,9 | 383,0 | 473,0 | 392,2 | 483,9 | 401,3 |
| кире кайтарылмый торган түләүләр | 44,8 | 45,0 | 45,3 | 45,5 | 45,8 | 46,0 | 46,3 | 46,5 | 46,8 | 47,0 | 47,3 | 47,5 |
| Чыгымнар – барлыгы, | 505,7 | 432,6 | 516,8 | 441,9 | 528,2 | 451,4 | 539,8 | 461,1 | 551,3 | 470,7 | 562,6 | 480,2 |
| шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү | | 366,0 | | 373,9 | | 381,9 | | 390,1 | | 398,2 | | 406,3 |
| Дефицит (профицит) | -31,9 | -31,9 | -31,8 | -31,8 | -31,7 | -31,7 | -31,6 | -31,6 | -31,5 | -31,5 | -31,4 | -31,4 |